**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

12.05.2021 534-п

Файдалы казылмаларның һәм җир асты сулары запасларына, файдалануга тапшырыла торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре турындагы геологик мәгълүматка, шулай ук гомумтаралган файдалы казылмалар запасларына һәм эчә торган су белән тәэмин итү яки техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган һәм алыну күләме тәүлегенә 500 кубик метрдан артмаган җир асты сулары запасларына дәүләт экспертизасы уздыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Файдалы казылмаларның һәм җир асты сулары запасларына, файдалануга тапшырыла торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре турындагы геологик мәгълүматка, шулай ук гомумтаралган файдалы казылмалар запасларына һәм эчә торган су белән тәэмин итү яки техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган һәм алыну күләме тәүлегенә 500 кубик метрдан артмаган җир асты сулары запасларына дәүләт экспертизасы уздыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Түбәндәгеләрне гамәлдән чыккан дип танырга:

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының гомумтаралган файдалы казылма запасларына, файдалануга тапшырыла торган җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләре турындагы геологик, икътисадый һәм экологик мәгълүматка дәүләт экспертизасы уздыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регла-

ментын раслау турында» 2013 елның 18 ноябрендәге 665-п номерлы боерыгын;

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының гомумтаралган файдалы казылма запасларына, файдалануга тапшырыла торган җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләре турындагы геологик, икътисадый һәм экологик мәгълүматка дәүләт экспертизасы уздыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 16 июнендәге 438-п номерлы боерыгын;

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының гомумтаралган файдалы казылма запасларына, файдалануга тапшырыла торган җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләре турындагы геологик, икътисадый һәм экологик мәгълүматка дәүләт экспертизасы уздыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 21 октябрендәге 1147-п номерлы боерыгын;

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 24 декабрендәге 1388-п номерлы боерыгының 1 пунктын.

3. Каты файдалы казылма геологиясе бүлегенә югарыда аталган Регламент нигезендә эшләр башкарылуын тәэмин итәргә.

4. Хокукый тәэмин итү бүлеге әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәү өчен җибәрергә.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары И.И.Гобәйдуллинга йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
12.05.2021 № 534-п .
боерыгы белән расланды

Файдалы казылмаларның һәм җир асты сулары запасларына, файдалануга тапшырыла торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре турындагы геологик мәгълүматка, шулай ук гомумтаралган файдалы казылмалар запасларына һәм эчә торган су белән тәэмин итү яки техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган һәм алыну күләме тәүлегенә 500 кубик метрдан артмаган җир асты сулары запасларына дәүләт экспертизасы уздыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Әлеге Регламент файдалы казылмаларның һәм җир асты сулары запасларына, файдалануга тапшырыла торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре турындагы геологик мәгълүматка, шулай ук гомумтаралган файдалы казылмалар запасларына һәм эчә торган су белән тәэмин итү яки техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган һәм алыну күләме тәүлегенә 500 кубик метрдан артмаган җир асты сулары запасларына дәүләт экспертизасы уздыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) тәртибен билгели.

1.2. Эчәргә яраклы су белән тәэмин итү яки техник су белән тәэмин итү максатларында файдаланыла торган һәм тәүлегенә 100 куб метрдан артмаган җир асты сулары кишәрлекләрендә җир асты сулары запасларына дәүләт экспертизасы уздырылырга тиеш түгел.

1.3. Мөрәҗәгать итүчеләр: җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиясе булган, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырган эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары, шул исәптән гади ширкәттә катнашучылар, чит ил гражданнары, юридик затлар.

1.4. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

1.4.1. Министрлыкның урнашу урыны: Казан шәһәре, Павлюхин урамы, 75.

Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча документлар һәм мөрәҗә-гатьләрне Министрлыкка җибәрү өчен почта адресы: 420049, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Павлюхин урамы, 75.

Министрлыкның эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, дүшәмбе-пәнҗешәмбе 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр, җомга 9.00 сәгать-тән 16.45 сәгатькә кадәр, төшке аш: 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гаризалар кабул итү графигы – шимбә, якшәмбе һәм эшләми торган бәйрәм көннәреннән тыш, көн саен, Министрлыкның эш сәгатьләрендә.

Җәмәгать транспортында килү:

«Филармония» тукталышына кадәр:

2, 4, 5, 25, 31, 37, 43, 47, 69, 69а, 74, 74а, 77 номерлы автобуслар;

6, 8, 12 номерлы троллейбуслар;

метро, «Сукно бистәсе» станциясенә кадәр.

Кертү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә.

1.4.2. Министрлыкның Минерал чимал һәм су ресурслары идарәсенең каты файдалы казылма геологиясе бүлегенең белешмә телефоны (алга таба – Бүлек): (843) 267-68-97, 264-59-68.

1.4.3. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://www.eco.tatarstan.ru. Электрон почта адресы: eco@tatarstan.ru.

1.4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, Министрлыкның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнаштырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://www.eco.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

1.5.5. Министрлыкның урнашкан урыны, белешмә телефоннары, эш графигы, шулай ук Министрлыкның электрон почта адресы турында мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырыла.

Мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен Министрлык биналарындагы мәгълүмат стендларында һәм Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү турында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3 - 2.5, 2.7, 2.8, 2.9, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган мәгълүматларны үз эченә ала.

1.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив-хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын да күрсәтеп) Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.

1.6. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеге – гомумтаралган файдалы казылмаларны үз эченә алган җир асты байлыклары кишәрлеге яки файдалы казылмалар алуга бәйле булмаган җирле һәм төбәк әһәмиятендәге җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен кулланыла торган җир асты байлыклары кишәрлеге, яисә эчә торган һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү (алга таба – эчә торган су белән тәэмин итү) яки техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган һәм табу күләме тәүлегенә 500 кубик метрдан артмаган, шулай ук бакчачылык коммерциясез ширкәтләрен һәм (яки) яшелчәчелек коммерциясез ширкәтләрен эчә торган яки техник су белән тәэмин итү максатлары өчен җир асты сулары булган җир асты байлыклары кишәрлеге;

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать турында сүз бара («Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 пункты (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон)). Гариза формасы әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән.

## 2. ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕ КҮРСӘТҮ СТАНДАРТЫ

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләп атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы | Файдалы казылмаларның һәм җир асты сулары запасларына, файдалануга тапшырыла торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре турындагы геологик мәгълүматка, шулай ук гомумтаралган файдалы казылмалар запасларына һәм эчә торган су белән тәэмин итү яки техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган һәм алыну күләме тәүлегенә 500 кубик метрдан артмаган җир асты сулары запасларына дәүләт экспертизасы уздыруны оештыру (алга таба – дәүләт экспертизасы) | «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе законының (алга таба – «Җир асты байлыклары турында» РФ законы) 29 статьясы;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы турындагы нигезләмәнең (алга таба – Нигезләмә) 3.3.11 пунктының алтынчы абзацы |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтә торган башкарма хакимият органы атамасы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы | Нигезләмәнең 3.3.11 пунктының алтынчы абзацы |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен | Файдалы казылмаларның һәм җир асты сулары запасларына, файдалануга тапшырыла торган җирле | Файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларына, файдалануга |

| | | |
|---|---|---|
| тасвирлау | әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре турындагы геологик мәгълүматка, шулай ук гомумтаралган файдалы казылмалар запасларына һәм эчә торган су белән тәэмин итү яки техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган һәм алыну күләме тәүлегенә 500 кубик метрдан артмаган җир асты сулары запасларына дәүләт экспертизасы бәяләмәсе (алга таба – дәүләт экспертизасы бәяләмәсе).<br>Комплектлы булмаган материалларны кире кайтару турында хат. | тапшырыла торган җир асты байлыклары кишәрлекләре турындагы геологик мәгълүматка дәүләт экспертизасы турында, аны уздырган өчен түләү күләмен билгеләү һәм аны алу тәртибе турында нигезләмәнең 24 пункты (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 11 февралендәге 69 номерлы карары белән расланган) (алга таба – 69 номерлы карар белән расланган Нигезләмә) |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе | 1. Тапшырылган документларның комплектлылыгын тикшерү срогы – гаризаны һәм документларны теркәгән көннән башлап 3 эш көне эчендә.<br>2. Дәүләт экспертизасын үткәрү вакыты әлеге Регламентның 2.5 пунктындагы 1 пунктчасында каралган срок узганнан соң 20 эш көненнән артмаска тиеш.<br>Кирәк булган очракта, Министрлык мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган материалларны тәгаенләштерә торган өстәмә мәгълүматны соратып алырга хокуклы. Бу вакытта экспертиза үткәрү вакыты озайтылырга мөмкин, ләкин 20 эш көненә кадәр генә.<br>3. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт экспертизасы бәяләмәсен җибәрү срогы, аны Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары | 69 номерлы карар белән расланган Нигезләмәнең 20, 21, 22, 25 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| булган документларны бирү (җибәрү) срогы | министры раслаганнан соң 5 эш көненнән дә артмаска тиеш.<br>Вәкилгә дәүләт экспертизасы бәяләмәсен яки комплектлы булмаган материалларны кире кайтару турында хат тапшыру мөрәҗәгать итүче килгән көнне гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору каралмаган. | |
| 2.5. Закон яисә бүтән норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | 1. Лицензия хуҗасыннан дәүләт экспертизасы уздыруга гариза (Регламентка 1 нче кушымта).Р410<br>2. Материаллар:<br>- гомумтаралган файдалы казылмаларның һәм эчәргә яраклы су белән тәэмин итү яки техник су белән тәэмин итү максатларында файдаланыла торган һәм алыну күләме тәүлегенә 500 куб. метрдан артмаган җир асты сулары запасларын исәпләү буенча;<br>- җир асты байлыкларында гомумтаралган файдалы казылмалар запасларын исәпләп чыгару өчен кондицияләрне техник-икътисадый нигезләү буенча;<br>- геологик разведкалау эшләре һәм әлеге запасларны яңадан бәяләү нәтиҗәләре буенча гомумтаралган файдалы казылмаларның һәм эчәргә яраклы су белән тәэмин итү яки техник су белән тәэмин итү максатларында файдаланыла торган һәм алыну күләме тәүлегенә 500 куб. метрдан артмаган җир асты сулары запаслары торышын оператив үзгәрүе буенча; | 69 номерлы карар белән расланган Нигезләмәнең 8, 10, 18 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | - ачыкланган файдалы казылма ятмаларында гомумтаралган файдалы казылмаларның һәм җир асты суларының запасларын исәпләү буенча;<br>- гомумтаралган файдалы казылмаларның запасларын гомуми таралган файдалы казылмаларның территориаль балансыннан чыгару буенча.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар Мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яки электрон чыганакларда түбәндәге ысулларның берсе аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>- шәхсән (ышаныч кәгазе нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән гамәл кылучы зат тарафыннан);<br>- кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы белән;<br>- «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша.<br>Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Интернет» челтәре аша, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итә торган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында түбәндәгеләр алына:<br>- гомумтаралган файдалы казылмаларга карамый торган файдалы казылмаларның запаслары буенча материалларга карата дәүләт экспертизасы бәяләмәсе (Идел буе федераль округы буенча Җир асты байлыкларыннан файдалану департаментыннан);<br>- план-картография материалына тауны бүлеп чыгару чикләрен билгеләп, тауны бүлеп бирү акты (Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең (Ростехнадзор) Идел буе идарәсеннән);<br>- документлар яңадан каралган очракта, Запаслар буенча дәүләт комитетының яки Запаслар буенча территориаль комиссиянең дәүләт экспертизасы бәяләмәсе күчермәсе («Идел буе федераль округы буенча Геологик мәгълүмат территориаль фонды» федераль бюджет учреждениесенең Татарстан филиалыннан);<br>- җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия күчермәсе (Идел буе федераль округы буенча Җир асты байлыкларыннан файдалану департаментыннан).<br>Мөрәҗәгать итүче шушы пункттагы белешмәләрдән торучы документларны, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә, тапшырырга хокуклы.<br>Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү өчен югарыда аталган документларны тапшырмавы дәүләт | 69 номерлы карар белән расланган Нигезләмәнең 19(1), 26 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.<br>Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.<br>Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:<br>- дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>- 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган документлар һәм мәгълүмат тапшыруны;<br>- 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен | |

| | | |
|---|---|---|
| | кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсә-телмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;<br>- 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статья-сының 1 өлешендәге 7.2 пункты нигезендә элегрәк электрон үрнәкләре таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтел-мәгән затның дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүе.<br>2. Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның тулы күләмендә тапшырылмавы. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр юк.<br>Гаризага теркәлгән материалларның каты файдалы казылмаларның запасларын исәпләп чыгару материалларының дәүләт экспертизасына тапшырыла торган материалларның составына һәм аларны рәсмиләштерү кагыйдәләренә карата Россия | РФ Табигать ресурслары министрлыгының 378 номерлы боерыгы |

| | | |
|---|---|---|
| | Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының 2011 елның 23 маендагы 378 номерлы боерыгы (алга таба – РФ Табигать ресурслары министрлыгының 378 номерлы боерыгы) белән расланган таләпләренә туры килмәве комплектлы булмаган материалларны мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирү нигезе булып тора. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын яки башка төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүле нигездә күрсәтелә.<br>Дәүләт экспертизасы уздыру өчен 69 номерлы карар белән расланган Нигезләмәнең V бүлеге нигезендә билгеләнгән күләмдә түләү билгеләнә.<br>Дәүләт экспертизасы үткәрү өчен түләү гариза тапшырганчыга кадәр башкарыла.<br>Дәүләт экспертизасын үткәрү өчен түләү түбәндәге реквизитлар буенча башкарыла:<br>Түләү алучының реквизитлары:<br>ТР буенча ФКИ, (ТР Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы, шәхси счет: 04112001010)<br>Казначылык счеты номеры 03100643000000011100<br>Бердәм казна счеты 40102810445370000079<br>Түләү алучының банкы: – Россия Банкының ТР Милли банкы бүлекчәсе//Татарстан Республикасы буенча ФКИ Казан шәһәре<br>БИК 019205400<br>ИНН 1659036508<br>КПП 165901001<br>ОКТМО 92701000 | Җир асты байлыклары турындагы законның 29 статьясы<br>69 номерлы карар белән расланган Нигезләмәнең 26, 26(1), 27 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | КБК 701 1 12 02052 01 0000 120<br>Түләүнең билгеләнеше: запасларга дәүләт экспертизасы үткәрү өчен түләү (җир асты байлыклары кишәрлегенең исемен күрсәтергә) | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләүнең күләмен хисаплау методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте, | Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану буенча | Россия Федерациясе Президентының |

| | | |
|---|---|---|
| дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры | кәгазьдә гариза тапшыру, чират булганда – иң күбе 15 минут.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артырга тиеш түгел.<br>Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы указы |
| 2.13. Дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында мөрәҗәгать итүче гаризасын теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да | Гариза кергән көннән алып бер эш көне эчендә.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза | Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән Министрлык биналарында һәм бүлмәләрендә күрсәтелә. | «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>Татарстан Республикасы Министрлар |

| | | |
|---|---|---|
| тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла.<br>Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озата йөри торган этләрдән файдаланучыларга да, биналардан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүдән файдалана алу шартларын тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:<br>бинага һәм бүлмәләргә каршылыксыз үтеп керү, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән каршылыксыз файдалана алу шартлары;<br>Министрлык территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, Министрлык бинасына һәм бүлмәләренә керү һәм чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;<br>күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;<br>инвалидларның бинадан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;<br>инвалидлар өчен кирәкле булган, ишетелә һәм күренә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльның нокталы шрифтлары | Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламент-ларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары |

| | | |
|---|---|---|
| | белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны дубльләштерү, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;<br>Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү;<br>хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү | |
| Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алуы һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән, үзара бәйләнешкә кереп, эшләү саны һәм аларның вакыты | Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү, тапшыру эшләре башкарыла торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;<br>Министрлык бинасының һәм бүлмәләренең инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алу мөмкинлеген бирә торган чаралар һәм җиһазлар белән тәэмин ителүе;<br>белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннарның кирәкле санда булуы; | |

| | | |
|---|---|---|
| буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтеннән һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгать) тапшыру | мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр күрсәтүдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтелүе.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;<br>Министрлык белгечләренең әлеге Регламентны бозуына нигезле шикаятьләрнең булмавы;<br>мөрәҗәгать итүченең Министрлык белгечләре белән бәйләнешкә керү саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар почта аша җибәрелгәндә, – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең белгеч белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү | |

| | | |
|---|---|---|
| юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән файдалану (шул исәптән тулы күләмдә) яки файдалана алмау мөмкинлеге | вакыты 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкка телдән (шәхсән яисә телефон аша) яки язмача мөрәҗәгать иткәндә, шулай ук «Интернет» челтәрендә Министрлык сайтыннан алынырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү (шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшыру) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урынында гамәлгә ашырылмый.<br>Экстерриториаль принцип һәм комплекслы мөрәҗәгать буенча дәүләт хезмәте күрсәтү гамәлгә ашырылмый | |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерри-ториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлек-ләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү | Мөрәҗәгать итүчегә консультация Бүлеккә шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта, почта аша мөрәҗәгать иткәндә, Министрлык сайты базасында оештырылган Интернет-кабул итү системасы ярдәмендә бирелергә мөмкин (http://www.eco.tatarstan.ru).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар Министрлык сайты базасында оештырылган Интернет-кабул итү системасы ярдәмендә электрон рәвештә тапшырылырга мөмкин (http://www.eco.tatarstan.ru). | |

| | | |
|---|---|---|
| үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | Документларны электрон рәвештә тапшыру өчен аларның «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә электрон рәвештә имзаланган булуы мәҗбүри шарт булып тора | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада да үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1. Файдалы казылмаларның һәм җир асты сулары запасларына, файдалануга тапшырыла торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре турындагы геологик мәгълүматка, шулай ук гомумтаралган файдалы казылмалар запасларына һәм эчә торган су белән тәэмин итү яки техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган һәм алыну күләме тәүлегенә 500 кубик метрдан артмаган җир асты сулары запасларына дәүләт экспертизасы уздыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

- дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, ярдәм күрсәтү;
- гаризаны һәм материаллар кабул итү, аларны теркәү;
- ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;
- алынган материалларның комплектлылыгын тикшерү һәм комплектлы документларны карап тикшерүгә кабул итү;
- дәүләт экспертизасы уздыруны оештыру;
- дәүләт экспертизасы бәяләмәсен мөрәҗәгать итүчегә тапшыру (җибәрү);
- техник хаталарны (язу, басма хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, ярдәм күрсәтү.

Мөрәҗәгать итүче Бүлеккә шәхсән, телефон аша һәм (яки) почта ярдәмендә (шул исәптән электрон) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән гаризаның формасы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүнең башка мәсьәләләре буенча да. Кирәк булганда Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәтеннән файдалануның башка мәсьәләләре буенча бирелгән консультацияләр.

3.3. Гаризаны һәм материаллар кабул итү, аларны теркәү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) шәхсән кәгазьдә, кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы белән, әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, Министрлыкка гариза тапшыра (җибәрә).

Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.

Гаризаны электрон формада җибәргән очракта, документларның сканер аша чыгарылган күчермәләре кушыла, гариза почтадан җибәрелгән, – мөрәҗәгать итүче тарафыннан таныкланган документлар.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза алынган көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырылган гариза һәм материаллар.

3.3.2. Министрлыкның документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге белгече:

гаризаны һәм аңа теркәлгән материалларны кабул итә һәм терки;

гаризаны һәм материалларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булуын тикшерә. Тикшерү Бүлек белгече катнашында гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, документларны кабул итүдән әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган баш тарту нигезләре булган очракта, Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту нигезләре булуы турында хәбәр итә һәм аңа, баш тарту өчен ачыкланган нигезләр эчтәлеген аңлатып, документларны кире кайтарып бирә. Мөрәҗәгать итүченең таләбе буенча баш тарту язмача рәвештә рәсмиләштерелә.

Мөрәҗәгать итүче гариза белән материалларны почта аша җибәргәндә, Бүлек белгече, баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, документларны аңа почта аша җибәрә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, гаризаны һәм теркәлгән документларны «Электрон Хөкүмәт» Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары электрон документ әйләнешенең бердәм ведомствоара системасында (алга таба – Электрон документ әйләнеше системасы) терки.

Эш вакыты булмаган чорда алынган гариза һәм материаллар алар алынган көннән соңгы беренче эш көнендә теркәлә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза алынган көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм министрга җибәрелгән гариза һәм документлар яки мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылган документлар.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм министрга җибәрелгән гариза һәм документлар яки мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Министр гариза һәм документларны карый һәм министр урынбасарына (җир асты байлыкларыннан файдалану мәсьәләләрен алып бара торган) карау өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: министр урынбасарына карау өчен җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.4. Министр урынбасары гариза һәм документларны карый һәм карау өчен Минераль чимал һәм су ресурслары идарәсе (алга таба – Идарә) җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Идарә җитәкчесенә карау өчен җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.5. Идарә җитәкчесе гариза һәм документларны карый һәм карау өчен Бүлек җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бүлек җитәкчесенә карау өчен җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.6. Бүлек җитәкчесе документлар алынган көнне җаваплы башкаручыны билгели, гаризаны һәм тапшырылган материалларны комплектлылыкка тикшерү өчен аңа тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә тапшырылган гариза һәм материаллар.

3.4. Ведомствоара мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү.

3.4.1. Бүлек белгече, мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхси инициатива буенча тапшырылмаган булсалар, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган тиешле дәүләт органнарыннан әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны бирү турында электрон формада рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыра һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә җибәрә:

гомумтаралган файдалы казылмаларга карамый торган файдалы казылмаларның запаслары буенча материалларга карата дәүләт экспертизасы бәяләмәсе күчермәсен бирү турында (Идел буе федераль округы буенча Җир асты байлыкларыннан файдалану департаментына);

план-картография материалына тауны бүлеп чыгару чикләрен билгеләп, тауны бүлеп бирү акты күчермәсен бирү турында (Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең (Ростехнадзор) Идел буе идарәсенә);

документлар яңадан каралган очракта, Запаслар буенча дәүләт комитетының яки Запаслар буенча территориаль комиссиянең дәүләт экспертизасы бәяләмәсе күчермәсен бирү турында («Идел буе федераль округы буенча Геологик мәгълүмат территориаль фонды» федераль бюджет учреждениесенең Татарстан филиалында);

Лицензия күчермәсен бирү турында (Идел буе федераль округы буенча Җир асты байлыкларыннан файдалану департаментына).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: анализланган һәм ведомствоара хезмәттәшлек системасы буенча тиешле дәүләт органнарына җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.4.2. Мәгълүмат белән тәэмин итүче затларның белгечләре әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша алынган рәсми мөрәҗәгать нигезендә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7.2 статьясының 3 пункты нигезендә соралган документларны (мәгълүматларны) законнарда билгеләнгән срокта бирә.

Процедураларның нәтиҗәсе: алынган документлар яки Министрлыкка җибәрелгән баш тарту турында белдерү.

3.5. Алынган материалларның комплектлылыгын тикшерү һәм комплектлы документларны карап тикшерүгә кабул итү.

3.5.1. Материалларның аларны карап тикшерү өчен җаваплы Бүлек белгеченә керүе административ процедураны башлап җибәрү нигезе булып тора, ул алынган документларга РФ Табигать ресурслары министрлыгының 378 номерлы боерыгы белән расланган каты файдалы казлымаларның запасларын исәпләп чыгура материалларының дәүләт экспертизасына тапшырыла торган материалларның составына һәм аларны рәсмиләштерү кагыйдәләренә карата таләпләргә туры килү-килмәү предметы буенча анализ ясый.

Комплектлы булмаган материалларны кире кайтару өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигез булган очракта, Бүлек белгече комплектлы булмаган материалларны мөрәҗәгать итүчегә кайтару турында хат проекты әзерли. Комплектлы материаллар карап тикшерүгә кабул ителә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны һәм аңа теркәлгән материалларны теркәгәннән соң 3 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән комплектлы булмаган материалларны кире кайтару турында хат яисә карап тикшерүгә кабул ителгән комплектлы материаллар.

3.6 Дәүләт экспертизасы уздыруны оештыру.

3.6.1. Комплектлы булмаган материалларны кире кайтару өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигез булмаса, Бүлек белгече Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы каршындагы Гомумтаралган файдалы казылмаларның запаслары буенча республика комиссиясенә (алга таба – эксперт комиссиясе) карап тикшерүгә тапшыру өчен документлар пакетын формалаштыра һәм аларны өйрәнү өчен аның әгъзаларына җибәрә.

Эксперт комиссиясе тарафыннан дәүләт экспертизасын үткәрү тәртибе Министрлык боерыгы белән раслана торган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы каршындагы Гомумтаралган файдалы казылмаларның запаслары буенча республика комиссиясе

турындагы Нигезләмәдә билгеләнә.

3.6.2. Документлар пакетын коллегиаль карау өчен Бүлек белгече экспертлар комиссиясе утырышын оештыра.

Дәүләт экспертизасы нәтиҗәләре дәүләт экспертизасы бәяләмәсендә бәян ителә, аны эксперт комиссиясе әгъзалары имзалый һәм имзалау көненнән соң 5 эш көне эчендә ул Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры тарафыннан раслана.

Тапшырылган материаллар эчтәлеге, нигезлелеге һәм күләме буенча гомумтаралган файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларының, файдалануга тапшырыла торган җир асты байлыклары кишәрлекләре турындагы геологик мәгълүматның, файдалы казылмалар алуга бәйле булмаганнарын да кертеп, җирле һәм төбәк әһәмиятендәге җир асты корылмаларын төзү һәм файдалану өчен яраклы җир асты байлыклары кишәрлекләре турындагы геологик мәгълүматның санын һәм сыйфатын объектив бәяләү мөмкинлеген бирмәсә һәм (яки), 69 номерлы карар белән расланган Нигезләмәнең 19(1) пунктының беренче абзацында каралган очракта, тапшырылган материаллар 69 номерлы карар белән расланган Нигезләмәнең III бүлеге нигезендә әзерләнгән дәүләт экспертизасы бәяләмәсенә туры килмәсә, дәүләт экспертизасы бәяләмәсендә материалларны тиешенчә эшләп бетерү кирәклеге турында күрсәтелергә тиеш.

Кирәк булган очракта, вәкаләтле эксперт органы мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган материалларны тәгаенләштерә торган өстәмә мәгълүматны соратып алырга хокуклы. Бу вакытта экспертиза үткәрү вакыты озайтылырга мөмкин, ләкин 20 эш көненә кадәр генә.

Дәүләт экспертизасы бәяләмәсендә булырга тиешле нәтиҗәләр:

- тапшырылган материалларда гомумтаралган файдалы казылмаларның һәм җир асты байлыкларындагы җир асты сулары запасларының санын һәм сыйфатын, ятмаларның яки аларның аерым өлешләренең сәнәгатьтә үзләштерүгә әзерлеген бәяләүнең дөреслеге һәм төгәллеге турында, шулай ук аларның сәнәгый әһәмиятләре;

- геологик өйрәнү, ятмаларны эшкәртү нәтиҗәләре буенча яки базар конъюктурасы үзгәрүгә бәйле рәвештә гомумтаралган файдалы казылмаларның һәм җир асты суларының запасларын яңадан бәяләүнең нигезлелеге турында;

- гомумтаралган файдалы казылмаларның запасларын территориаль баланска куюның һәм территориаль баланстан чыгаруның, шулай ук запаслар үзгәрүне оператив исәпкә алуга бәйле үзгәрешләрне кертүнең нигезлелеге турында;

- файдалы казылмалар алуга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм файдалану өчен җир асты байлыклары кишәрлекләреннән куркынычсыз файдалану мөмкинлекләре турында.

3.6.1, 3.6.2 пунктчаларда билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.5.1 пунктында каралган процедура тәмамланганнан соң 20 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: расланган дәүләт экспертизасы бәяләмәсе.

3.7. Дәүләт экспертизасы бәяләмәсен мөрәҗәгать итүчегә тапшыру (җибәрү).

3.7.1. Дәүләт экспертизасы бәяләмәсе, аңа теркәлә торган хат белән, мөрәҗәгать итүчегә тапшырыла (җибәрелә).

Теркәлә торган хат белән дәүләт экспертизасы бәяләмәсе мөрәҗәгать итүченең кулына тапшырыла яки дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресы буенча язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында) җибәрелә.

Вәкилгә дәүләт экспертизасы бәяләмәсен бирү мөрәҗәгать итүче килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Дәүләт экспертизасы бәяләмәсен җибәрү алдагы процедура тәмамланган көннән соң 5 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлә торган хат белән мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән (тапшырылган) дәүләт экспертизасы бәяләмәсе.

3.8. Техник хатаны төзәтү.

3.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Бүлеккә түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (3 нче кушымтага ярашлы форма буенча);

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хатасы булган документ;

техник хатасы барлыгын дәлилли торган, юридик көчкә ия документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдәге техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән тапшырыла яисә почта аша (шул исәптән электрон почта ярдәмендә дә) җибәрелә.

3.8.2. Министрлыкның документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге белгече техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә, кушымта итеп бирелгән документлары белән гаризаны терки һәм аларны Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Бүлек белгеченә карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.8.3. Бүлек белгече документларны карый һәм, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында, әлеге Регламентның 3.6 һәм 3.7 пунктларында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм техник хатаның төзәтелгән булуын раслый торган документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) тапшыра (җибәрә).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хатаны ачыклаганнан соң яисә техник хатаны төзәтү турында гаризаны теркәү датасыннан соң 5 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаның төзәтелгән булуын раслый торган, бирелгән (җибәрелгән) документ.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедураларында билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге саклануны даими рәвештә тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган идарәләрнең (бүлекләрнең) җитәкчеләре тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләренең үтәлүенә һәм башкарылуына тикшерүләр үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла. Контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның вәкаләтләре Министрлык идарәләре (бүлекләре) турындагы нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

4.3. Агымдагы контрольлек Министрлыктагы вазыйфаи затларның әлеге Регламентта һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы тикшереп тору даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору тикшерүләр үткәрүне, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына кагылышлы шикаятьләрне үз эченә алган мөрәҗәгатьләрне карап тикшерүне, алар буенча карарлар кабул итүне һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедуралар үтәлешен контрольдә тоту рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

- эшнең алып барылуына;
- документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (әлеге Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;
- документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;
- дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) мөрәҗәгать итүчеләр Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затлары гамәлләренең (гамәл кылмавының) үзләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.6. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә Мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.7. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүен контрольдә тоту дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Идарә (бүлек) эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәрге тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе.

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты яисә дәүләт граждан хезмәткәре карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Министрлыкка шикаять белдерергә хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә министр тарафыннан кабул ителгән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелә.

Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатьне теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартылганда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту очрагында, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән басма хата-

ларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.2. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Дәүләт хезмәтеннән файдаланучылар тарафыннан шикаять почта аша, «Интернет» челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://eco.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан (https://uslugi.tatarstan.ru), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (https://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.3. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы 5 эш көне эчендә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турындагы белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең

карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

5.5. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аның дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча министр түбәндәге карарларның берсе кабул итә:

1) шикаять канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән, дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка формаларда да;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән соңга калмыйча, Мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә, аның ихтыяры буенча, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында Министрлыкта гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

5.10. Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, яки дәүләт хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җайга салына.

Файдалы казылмаларның һәм җир асты сулары запасларына, файдалануга тапшырыла торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре турындагы геологик мәгълүматка, шулай ук гомумтаралган файдалы казылмалар запасларына һәм эчә торган су белән тәэмин итү яки техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган һәм алыну күләме тәүлегенә 500 кубик метрдан артмаган җир асты сулары запасларына дәүләт экспертизасы уздыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

(киңәш ителә торган рәвеше)

Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры
А.В. Шадриковка
кемнән

______________________________
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

______________________________
(предприятиенең, шәхси эшкуарның исеме)

лицензия № __________ серия ____________
җир асты байлыклары кишәрлеге
______________

Дәүләт экспертизасы үткәрү турында гариза

Татарстан Республикасы буенча файдалы казылмаларның (җир асты суларының) запасларына, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеге турындагы геологик мәгълүматка дәүләт экспертизасы уздыруыгызны үтенәм____________________________________________,
(файдалы казылманың исеме һәм төре)

урнашкан урыны:______________________________________________.
(урнашу районы, урыны)

Теркәлә торган документлар исемлеге:
1. ______________________________________________
2. ______________________________________________
3. ______________________________________________
4. ______________________________________________
5. ______________________________________________
(теркәлә торган документларның барлык исемлеген күрсәтергә)

Җитәкче ____________________ /___________________________/
(имза) (тулы имза)

Башкаручы (Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта) тулысынча)
(Элемтә өчен телефон, E-mail)

Файдалы казылмаларның һәм җир асты сулары запасларына, файдалануга тапшырыла торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре турындагы геологик мәгълүматка, шулай ук гомумтаралган файдалы казылмалар запасларына һәм эчә торган су белән тәэмин итү яки техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган һәм алыну күләме тәүлегенә 500 кубик метрдан артмаган җир асты сулары запасларына дәүләт экспертизасы уздыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

(киңәш ителә торган рәвеше)

Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры
А.В. Шадриковка
кемнән
___________________________________
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме

(соңгысы – булган очракта)
___________________________________
(предприятиенең, шәхси эшкуарның исеме)

лицензия № __________ серия ___________
җир асты байлыклары кишәрлеге _______
___________________________________

Техник хатаны (язу, басма хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән техник хата (язу, басма хаталары, грамматик яисә арифметик хаталар) турында хәбәр итәм ______________________________
(хезмәт күрсәтүнең атамасы)

Язылган:_________________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар: _______________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны (язу, басма хатасын, грамматик яисә арифметик хатаны) төзәтүегез һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегез турында сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

Техник хатаны (язу, басма хатасын, грамматик яисә арифметик хатаны) төзәтү турындагы гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, түбәндәгечә хәбәр итүегезне үтенәм:

e-mail:________________________ адресына электрон документ рәвешендә;

______________________________ адресы буенча кәгазь документның таныкланган күчермәсе рәвешендә почта аша.

_______________ _________________ (_________________________)
(дата) (имза) (Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)

Башкаручы (Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта) тулысынча)
(Элемтә өчен телефон, E-mail)

Файдалы казылмаларның һәм җир асты сулары запасларына, файдалануга тапшырыла торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре турындагы геологик мәгълүматка, шулай ук гомумтаралган файдалы казылмалар запасларына һәм эчә торган су белән тәэмин итү яки техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган һәм алыну күләме тәүлегенә 500 кубик метрдан артмаган җир асты сулары запасларына дәүләт экспертизасы уздыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

## Файдалы казылмаларның һәм җир асты сулары запасларына, файдалануга тапшырыла торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре турындагы геологик мәгълүматка, шулай ук гомумтаралган файдалы казылмалар запасларына һәм эчә торган су белән тәэмин итү яки техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган һәм алыну күләме тәүлегенә 500 кубик метрдан артмаган җир асты сулары запасларына дәүләт экспертизасы уздыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы

| Вазыйфа, фамилия, исем, ата исеме | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры | 267-68-01 | eco@tatar.ru. |
| Министр урынбасары | 267-68-19 | Ilnur.Gubaydullin@tatar.ru |
| Минерал-чимал һәм су ресурслары идарәсе җитәкчесе | 267-68-95 | Aleksey.Chinarev@tatar.ru |
| Каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге җитәкчесе | 267-68-97 | Svetlana.Shutnikova@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфа, фамилия, исем, ата исеме | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Җир асты биләмәләреннән, табигать ресурсларынан файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре бүлеге җитәкчесе | 264-77-78 | Marat.Fashutdinov @tatar.ru |